КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2024 ел, 29 март г.Казань № 201

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасында сәнәгать сәясәте турында» 2016 елның 21 апрелендәге 24-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законын гамәлгә ашыру чаралары хакында» 2018 ел, 15 декабрь, 1144 нче карарына үзгәрешләр кертү турында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасында сәнәгать сәясәте турында» 2016 елның 21 апрелендәге 24-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законын гамәлгә ашыру чаралары хакында» 2018 ел, 15 декабрь, 1144 нче карарына (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2020 ел, 12 ноябрь, 1016 нчы; 2023 ел, 23 октябрь, 1338 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

преамбулада «индустриаль (сәнәгать) паркларны,» сүзләреннән соң «сәнәгать технопаркларын, югары технологияләр өлкәсендәге технопаркларны,» сүзләрен өстәргә;

1 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1. Татарстан Республикасы территориясендә индустриаль (сәнәгать) паркларга, сәнәгать технопаркларына, югары технологияләр һәм сәнәгать кластерлары өлкәсендәге технопаркларга карата сәнәгать өлкәсендәге эшчәнлекне стимуллау чараларын куллану тәртибен (карарга теркәлә) расларга.»;

әлеге карар белән расланган Татарстан Республикасы территориясендә индустриаль (сәнәгать) паркларга, сәнәгать технопаркларына һәм сәнәгать кластерларына, сәнәгать технопаркларының идарәче компанияләренә һәм сәнәгать технопаркы составындагы технологик инфраструктура һәм сәнәгать инфраструктурасы объектларыннан файдаланучы сәнәгать өлкәсендәге эшчәнлек субъектларына карата сәнәгать өлкәсендәге эшчәнлекне стимуллау чараларын куллану тәртибендә:

исемен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Татарстан Республикасы территориясендә индустриаль (сәнәгать) паркларга, сәнәгать технопаркларына, югары технологияләр һәм сәнәгать кластерлары өлкәсендәге технопаркларга карата сәнәгать өлкәсендәге эшчәнлекне стимуллау чараларын куллану тәртибе»;

1 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1. Әлеге Тәртип «Татарстан Республикасында сәнәгать сәясәте турында» 2016 елның 21 апрелендәге 24-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законын гамәлгә ашыру максатларында индустриаль (сәнәгать) паркның идарәче компаниясенә, сәнәгать өлкәсендә индустриаль (сәнәгать) парк составында урнашкан сәнәгать инфраструктурасы объектларыннан файдаланучы эшчәнлек субъектларына, сәнәгать технопаркының идарәче компаниясенә, сәнәгать өлкәсендә сәнәгать технопаркы составында урнашкан технологик инфраструктура һәм сәнәгать инфраструктурасы объектларыннан файдаланучы эшчәнлек субъектларына, югары технологияләр өлкәсендәге технопаркның идарәче компаниясенә, сәнәгать продукциясен җитештерүне тәэмин итү һәм (яисә) базарга яңа продуктлар, технологияләр һәм (яисә) хезмәт күрсәтүләр чыгару максатларында югары технологияләр өлкәсендәге технопарк составында урнашкан технологик инфраструктура, транспорт инфраструктурасы һәм коммуналь инфраструктура объектларын, фәнни-техник эшчәнлекне гамәлгә ашыру, һәм (яисә) инновацион эшчәнлек, һәм (яисә) мәгълүмат технологияләре өлкәсендәге эшчәнлек алып бару өчен билгеләнгән биналар, төзелмәләр, корылмаларны файдаланучы юридик затларга, индивидуаль эшмәкәрләргә (алга таба – сәнәгать өлкәсендә эшчәнлек субъектлары), шулай ук сәнәгать кластерларына карата сәнәгать өлкәсендәге эшчәнлекне стимуллау чараларын куллануны җайга сала.»;

3 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3. Сәнәгать өлкәсендәге эшчәнлекне стимуллау чаралары, сәнәгать өлкәсендәге эшчәнлек субъектлары Россия Федерациясе Хөкүмәте тарафыннан билгеләнгән таләпләргә һәм, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты тарафыннан билгеләнсә, өстәмә таләпләргә туры килгән очракта, Татарстан Республикасы бюджеты мөлкәте һәм акчасы исәбеннән гамәлгә ашырыла.»;

әлеге Тәртипкә 1 нче кушымтада:

нумерация башисемен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Татарстан Республикасы территориясендә индустриаль (сәнәгать) паркларга, сәнәгать технопаркларына, югары технологияләр һәм сәнәгать кластерлары өлкәсендәге технопаркларга карата сәнәгать өлкәсендәге эшчәнлекне стимуллау чараларын куллану тәртибенә 1 нче кушымта»;

2 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2. Татарстан Республикасы Сәнәгать һәм сәүдә министрлыгы (алга таба – вәкаләтле орган) Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасында сәнәгать сәясәте турында» 2016 елның 21 апрелендәге 24-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законын гамәлгә ашыру чаралары хакында» 2018 ел, 15 декабрь, 1144 нче карары белән расланган Татарстан Республикасы территориясендә индустриаль (сәнәгать) паркларга, сәнәгать технопаркларына, югары технологияләр һәм сәнәгать кластерлары өлкәсендәге

технопаркларга карата сәнәгать өлкәсендәге эшчәнлекне стимуллау чараларын куллану тәртибенә 2 нче кушымтада бирелгән форма буенча Реестр алып бара.»;

әлеге Тәртипкә 2 нче кушымтаның нумерация башисемен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Татарстан Республикасы территориясендә индустриаль (сәнәгать) паркларга, сәнәгать технопаркларына, югары технологияләр һәм сәнәгать кластерлары өлкәсендәге технопаркларга карата сәнәгать өлкәсендәге эшчәнлекне стимуллау чараларын куллану тәртибенә 2 нче кушымта».

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин